| ГЛАВА<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 октябрь 2022 ел с.Шалты № 13

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

2022 елның 18 ноябренә 10:00 сәгатькә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Шалты авылы, Совет урамы, 63Б адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты.

2022 елның 18 ноябренә 14:00 сәгатькә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Шалты авылы, Новая урамы, 6 адресы буенча урнашкан МББУ “Шалты төп гомуми белем бирү мәктәбе”.

3. Гражданнар исемлеген территориаль принцип нигезендә түбәндәгечә бүләргә:

1. 1 нче этап: Тукай урамында яшәүчеләр, № 1-№ 43 йортлар, Совет урамында яшәүчеләр, № 1-№ 105 йортлар, Киров урамында яшәүчеләр, №1-№94 йортлар, Чкалов урамында яшәүчеләр, № 1-№ 44 йортлар.

2. 2 нче этап: Новая урамында яшәүчеләр, № 1/1 - № 5/2 йортлар, Мира урамында яшәүчеләр, № 1- № 64 йортлар, Садовая урамында яшәүчеләр, №1-№9 йортлар.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елда Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Шалты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

- Зиратны төзекләндерү һәм карап тоту

- Юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (кар һәм чүп үләннәреннән чистарту)

2. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә, Баулы муниципаль районы сайтында  һәм Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга, Шалты авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шалты авыл
җирлеге Башлыгы　　　　　　　　　　З.Х. Фаткуллин